Караллы:	Килешенде:	Расланды:
гуманитар МБ утырышында	укыту-тәрбия эшләре буенча директор	Мәктәп директоры_____/Р.И.Солягина/
җитәкче_____/ Р.Р.Вәлиева/	урынбасары _____/Л.М.Леонтьева/	Боерык № 74-о от 31.08. 2020 ел
Беркетмә № 1. 31.08. 2020 ел.	31.08. 2020 ел.	

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

“Нармонка урта гомуми белем мәктәбе”

Югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Вәлиева Рәмзия Рәстәм кызының 7 нче сыйныф өчен 2020 – 2021 нче уку елына

туган (татар) әдәбиятыннан эш программасы

2020-2021 ел

2020-2021 нче уку елы

Тематик - укыту планы

Предмет: әдәбият

Класс: 7

Укытучы: Вәлиева Р.Р.

Сәгатьләр саны:

барлыгы – 34 сәгать; атнага – 1 сәгать

Контроль эшләр: КТУ- 4сәг., сочинение – 4 сәг., тест – 2сәг.

План Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа (т ө з ү ч е - а в т о р л а р ы : Ф. Х. Җәүһәрова, Казан 2013) нигезендә төзелде

Татар әдәбияты, 7 нче сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) Ә.Н.Нәҗипова, Л.Ш. Исхакова Казан Татарстан китап нәшрияты. 2015

Татар әдәбиятыннан эш программасы
7 нче сыйныф
(34 сәг)

Аңлатма язуы

Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:

1. “Мәгариф турында” РФ һәм РТ Законнары.
   - Федеральный закон от 29.12.2012г. №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»,
   - Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования, утвержденный приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17.12.2010г. №1897»
   - «Порядком организции и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам начального общего, основного обшего и среднего общего образования, утвержденным приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 30.08.2013г. № 1015»
2. Образовательная программа основного общего образования в соответствии с ФГОС ООО МБОУ Нармонской СОШ (утверждена приказом № 70-о от 29.08.2015 г.(1) внесены изменнения приказ № 79-о от 27.08.2016 год.; 2) внесены изменения, приказ 118-о от 23.10. 2017)
2. Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа (т ө з ү ч е - а в т о р л а р ы : Ф. Х. Җәүһәрова, Казан 2013).
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы МБОУ “Нармонка урта гомуми белем мәктәбе”нең 2020-2021 нчы уку елына “Укыту планы” (Принято решением педсовета, протокол №8 от 27 августа 2020 года и утвержденного приказом №73-о от 27.08.2020 г.)

4. Федераль дәреслекләр исемлеге (федеральный перечень учебников, рекомендуемых к использованию при реализации имеющих государственную аккредитацию образовательных программ начального общего, основного общего, среднего общего образования (Список учебников МБОУ Нармонской средней общеобразовательной школы Лаишевского муниципального района Республики Татарстан на 2020-2021 учебный год (Принято решением педсовета, протокол №8 от 27 августа 2020 года и утвержденного приказом №73-о от 27.08.2020 г.)

Урта сыйныфларда әдәбиятны өйрәнү түбәндәге **максатларны** алга куя:

- татар әдәбияты текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү; төп әдәби-тарихи мәгълүматлардан, әдәби барышны тәэмин итүче төп әдипләр иҗаты турында хәбәрдәр булу һәм гомум әдәби-теоретик төшенчәләрне татар әдәбиятына мөнәсәбәтле куллана **белү**.
- татар әдәбияты тарихының төп фактларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау күнекмәләре формалаштыру; әсәрләрдәге конкрет-тарихи һәм гомумкешелек эчтәлекне күрә белү; телдән һәм язма чыгышларда әдәби тел байлыгыннан дөрес файдалану **күнекмәләре булдыру**.
- әдәби текстны эмоциональ кабул итүне, образлы һәм аналитик фикерләүне, иҗади күзаллауны; китап укучы культурасын һәм автор позициясен аңлауны; сәнгать төрләре белән берлектә әдәбиятның сүз сәнгате буларак үзенчәлеге турында карашны; матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру; укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен **үстерү**.
- татар әдәбияты, мәдәнияте белән кызыксыну, дөньяга гуманлы караш, татар халкының мәдәни кыйммәтләренә хөрмәт булдыру, ягъни рухи дөньясы бай һәм башка мәдәниятләрне хөрмәт белән кабул итүче шәхес **тәрбияләү**.

Татар әдәбияты укытуның **бурычлары:**

1. Укучының татар әдәбиятын үзләштерүенә, текстны аңлап, йөгерек һәм сәнгатьле итеп укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү.
2. Балаларны татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр- музыкасы, театры, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү.
3. Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы, чит илләрдәге милләттәшләребез тормышы турында мәгълүматлар бирү.
4. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша яшүсмерләрдә Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм гомумән кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү. Шулай ук хезмәт тәрбиясе һәм эстетик тәрбия бирү.

УКЫТУНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

Урта һәм югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәбиятны мөстәкыйль укып, аңларлык күнекмәләр булдыру;
- татар сүз сәнгатен рус һәм дөнья әдәбияты фонында кабул итәргә өйрәтү;
- татар әдәби теле нормаларын саклап язу һәм сөйләү күнекмәләре булдыру;

- кирәкле мәгүлүмат һәм белемнәрне төрле чыганакладан табу, алардан мөстәкыйль рәвештә кулланырга өйрәтү.

Урта һәм югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предмет нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

Танып-белү өлкәсендә:

- татар әдәби текстны кабул итәргә һәм аңларга, иҗат ителгән чор белән тарихи-мәдәни бәйләнешләрен һәм аңа салынган мәңгелек кыйммәтләрне күзалларга өйрәтү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен беркадәр билгели, геройларын бәяли алуына ирешү;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларына кагылышлы төп фактларны белүенә ирешү;
- татар әдәбияты текстларын рус әдәбияты әсәрләре белән гомумкешелек кыйммәтләренә мөнәсәбәттә чагыштыру күнекмәләре формалаштыру;
- *бәяләү өлкәсендә*:
- татар әдәбиятына хас рухи-әхлакый кыйммәтләрне, әдәби-эстетик үзенчәлекләрне аңларга өйрәтү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү;
- баланың үзаңын үстерү, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- татар әдәбияты үрнәкләренә үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

коммуникатив яктан:

- татар әдәбияты әсәрләрен аңлап укый һәм кабул итә алуга ирешү;
- әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку, өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерергә өйрәтү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары аша эзләү күнекмәсе булдыру;
- укучының мөстәкыйль, иҗади фикерләвен активлаштыру;
- әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча татар телендә иҗади эшләр башкарырга өйрәтү.

эстетик яктан:

- әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен һәм милли үзенчәлекләрен тою хисе формалаштыру;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

Эш программасының эчтәлеге

1. Укыту планында 7 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан атнага 1 сәгать вакыт бирелә . Татар әдәбияты, 7 нче сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) /Ә.Н.Нәҗипова, Л.Ш. Исхакова / Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2015, Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программага (т ө з ү ч е - а в т о р л а р ы : Ф. Х. Җәүһәрова, Казан 2013) нигезләнеп төзелде. Программада 68 сәгать каралган, ә укыту планында атнага 1 сәгать. Барысы -34 сәгать. Әсәрләрне уку һәм өйрәнү – 25 сәгать. Класстан тыш уку – 4 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – 4 сәгать бирелде.

№	Төп темалар	Сәг.	Белем һәм күнекмәләр
1	Халык авыз иҗаты. Дастан	1	Дастан турында төшенчә. “Идегәй” дастанын өйрәнү
2	Язучы иҗатына анализ **Габдулла Тукай**	1	Тормыш юлы. Иҗаты. “Милли моңнар” “Кышкы кич” шигырьләренә анализ. “**Шүрәле**” поэмасы, “**Туган авылым**” шигыре, шигырьләренә анализ. “**Пар ат**” шигыре
3	**Галимҗан Ибраһимов**	2	Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. “**Алмачуар”** хикәясен өйрәнү, анализлау.”**Сөю-сәгадәт”.** “**Табигать балалары**” әсәре. Хикәя турында төшенчә
4	Һади Такташ	1	Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. “Ак чәчәкләр” шигыре, “Алсу” поэмасы
5	Гадел Кутуй	2	Тормыш юлы, иҗады турында белешмә. “**Рәссам**” әсәре, “Рөстәм маҗаралары” повестен өйрәнү, анализлау.
6	**Мәҗит Гафури**	1	Тормыш юлы, иҗады турында белешмә . “**Ана**” шигырен уку, анализлау
7	Фатих Кәрим	1	“Бездә яздыр”, “Сөйләр сүзләр бик күп алар” шигырьләренә анализ.
8	Хәсән Туфан	2	Тормыш юлы. Иҗаты. Шигырьләренә анализ: “Киек казлар”, “Кайсыгызның кулы җылы” Әдәбият теориясе: Шигырь төзелеше. Лирик герой. Күчерелмә мәгънә.

			Метафора. Гипербола. Символ.
9	Гомәр Бәширов	1	Тормыш юлы. Иҗаты. “Менә сиңа мә!” хикәясе
10	Ибраһим Гази	2	Тормыш юлы. Иҗаты. “Йолдызлы малай” әсәрен өйрәнү, анализлау
11	**Әмирхан Еники**	2	Тормыш юлы. Иҗаты.”**Кем җырлады**?”, “**Матурлык” , “Туган туфрак”** әсәрләрен өйрәнү, анализ. Әдәбият теориясе: Психологизм.
12	Сибгат Хәким	1	Тормыш юлы. Иҗаты. “Торыгыз Мусалар!” , “Татарлар елмаеп үлделәр”, “Бакчачылар” шигырьләренә анализ. Әдәбият теориясе: Поэма.
13	Нәҗар Нәҗми	1	Тормыш юлы. Иҗаты. “Татар теле” шигыре
14	Гөлшат Зәйнәшева	1	Тормыш юлы. Иҗаты. “Туган җирем - Татарстан” шигырен өйрәнү.
15	Мөхәммәт Мәһдиев	2	Тормыш юлы. Иҗаты. “Без кырык беренче ел балалары” әсәре.
16	Туфан Миңнуллин	2	Тормыш юлы. Иҗаты. “Монда тудык, монда үстек” әсәре. Әдәбият теориясе: Драма.
17	Марсель Галиев	1	Тормыш юлы. Иҗаты. ” **Нигез**” әсәрен өйрәнү
18	Иван Крылов	1	Тормыш юлы. Иҗаты. “Аккош, Чуртан һәм Кысла”, “Бүре белән Бәрән” мәсәлләре. Әдәбият теориясе: Мәсәл. **Мәҗит Гафури** “**Ана**”
19	Александр Пушкин	1	Тормыш юлы. Иҗаты. “Җырчы” “Кышкы кич” шигырьләре
20	Класстан тыш уку	4	Г.Тукай “Мәсәлләр”. Г.Ибраһимов “**Табигать балалары**”. Г.Кутуй “**Рәссам”**. Г.Кашапов “Киек каз юлы”
21	Бәйләнешле сөйләм үстерү	4	

Әдәби әсәрләрне танып-белү буенча төп эшчәнлек төрләре:

- Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
- сәнгатьле уку;
- кабатлап сөйләүнең төрле төрләре (тулы итеп, кыскача, сайлап, аңлатмалар белән, иҗади бирем белән);
- шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
- әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү;
- план төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә (отзыв) язу;
- сочинение элементлары белән изложение язу;
- әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу;
- тема, проблема, жанр уртаклыклары нигезендә татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып бәяләү;

- рус телендәге әдәби текстларны татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итү.

Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:

- сүз сәнгатенең образлы табигате;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеге;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактлары;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләр;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләреңне дәлилли белү;
- укыган әсәрләргә бәяләмә (отзыв) язу;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

Укыту – методик комплекты

Дәреслек: Татар әдәбияты, 7 нче сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) /Ә.Н.Нәҗипова, Л.Ш. Исхакова / Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2015

Информацион-методик кулланма

.

1. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма/Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов,В.Р.Әминева.-Казан:Мәгариф,2005
2. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. /Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2000
3. Әдәбият дәресләрендә /Ф.Ә.Гайфуллина - Казан “Яңалиф” нәшрияты,2006
4. Сочинени язарга өйрәнәбез/ З.Н.Хәбибуллина, Р.В..Миңнуллина - Казан “Яңалиф” нәшрияты,2002
5. Сәнгатьле сөйләм. Г.С.Нуриев. Казан.”Мәгариф” 2009.
6. Татар теле һәм әдәбияты укыту тәҗрибәсеннән. “Яңалиф”2003. Гөлнур Каюмова.
7. Әдәбият дәреслекләре буйлап. Н.С.Гыймадиева, Ә.Г.Билалова. “Яңалиф”2006.
8. Үз илемдә, үз телемдә. Ф.М.Зиннурова. “Мәгариф”2009.
9. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына. “Яңалиф”2005.
10. Хрестоматияләр, вакытлы матбугат, дискалар, интернет-ресурслар.

Практик һәм язма эшләр графигы

Класстан тыш уку	Тест	Сочинение (хикәя)

Календарь -тематик план

№	Дәрес темасы	Сәгать саны	Материалны үзләштерүдә көтелгән нәтиҗә	Дата	
				План	Факт
1	Халык авыз иҗаты. Дастан	1	Халык авыз иҗаты турында төшенчә. Дастан. “Идегәй” дастанын өйрәнү	4.09	
2	**Габдулла Тукай**. “**Шүрәле**” поэмасы“ **Туган авылым”** шигыре. “Милли моңнар” “Кышкы кич” шигырьләре. **“Пар ат”** шигыре	1	Шагыйрь иҗаты турында белешмә. Әсәр белән танышу. Шагыйрь балачагының бирелеше. Поэма белән танышу. Әсәрдә туган якка мәхәббәтнең чагылы -шы, табигатьнең сурәтләнүе	11.09	
3	Г. Тукай . Мәсәлләр.	1	Укучылдарның белемнәрен тикшерү . Укучыларның йөгерек укуларына ирешү		
4	Галимҗан Ибраһимов иҗаты. “**Сөю-сәгадәт**” әсәре. “**Алмачуар”** хикәясе	1	Тормыш юлы , күпкырлы эшчәнлеге. Хикәяне аңлап уку. Атка булган мәхәббәтнең сурәтләнүе. Закир тормышындагы үзгәрешләр. Әсәр дә гореф-гадәтләрнең бирелеше		
5	**Г.Ибраһимов “Табигать балалары”** әсәре	1	Эчтәлек өстендә эшләү. Темасын, проблемасын билгеләү. Геройлар- га характеристика бирү. Революю- циягә кадәр авыл тормышының , кеше психологиясенең бирелеше		
6	КТУ**. Г.Ибраһимов “Табигать балалары” әсәре**	1	Эчтәлек өстендә эшләү. Темасын, проблемасын билгеләү		

7	Һади Такташ. “Ак чәчәкләр” шигыре, “Алсу” поэмасы	1	Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Әсәрләренең эчтәлеге өстендә эшләү. Темасын, проблемасын ачу.		
8-9	Гадел Кутуй. **“Рәссам”** әсәре	2	Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Әсәрләре белән танышу. Сугыштагы кешенең кичерешләрендә Туган ил образы		
10	КТУ. Г. Кутуй. Рәссам	1	Укучылдарның белемнәрен тикшерү . Укучыларның йөгерек укуларына ирешү		
11	**Мәҗит Гафури . “Ана”** шигыре	1	Тормыш юлы , иҗаты турында кыскача белешмә. Шигырьне сәнгатьле итеп уку күнекмәләре бирү. Темасын билгеләү. Шигырь аша милләт язмышын тасвирлау		
12	Фатих Кәрим . “Бездә яздыр”, “Сөйләр сүзләр бик күп алар” шигырьләре	1	Тормыш юлы , иҗаты турында кыскача белешмә. Шигырьне сәнгатьле итеп уку күнекмәләре бирү. Темасын билгеләү.		
13	.БСҮ. Сочинение “Кирәкми безгә сугыш”	1	Үз фикереңне язмача белдерә белү		

14-15	Хәсән Туфан. “Киек казлар”, “Кайсыгызның кулы җылы” шигырьләре	2	Тормыш юлы , иҗаты турында кыскача белешмә. Шигырьне сәнгатьле итеп уку күнекмәләре бирү. Темасын билгеләү. Әдәбият теориясе: Шигырь төзелеше. Лирик герой. Күчерелмә мәгънә. Метафора. Гипербола. Символ.		
16	Гомәр Бәширов. “Менә сиңа мә!” әсәре	1	Тормыш юлы , иҗаты турында кыскача белешмә. Әсәрне анализлау.		
17-18	Ибраһим Гази. “Йолдызлы малай” әсәре	2	Тормыш юлы , иҗаты турында кыскача белешмә. “Йолдызлы малай” әсәрендә батырлык сыйфатының бирелеше.		
19	БСҮ. Сочинение “Мин Илгизәр урынында булсам нишләр идем?”	1	Үз фикереңне язмача белдерә белү		
20	КТУ. Г. Кашапов “Киек каз юлы” әсәре	1	Әсәрне өйрәнүне давам итү. Әсәр- дәге проблема, тема. Төп геройга характеристика.Туган җир төшен -чәсенең бирелүе		
21-22	Әмирхан Еники. **“Кем җырлады?”, “Матурлык”** хикәяләре. **“Туган туфрак**” әсәре	2	Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә. Хикәя белән танышу. Сугыш китергән афәтне күзаллау. Әсәрне аңлап уку. Җанлы образ -ларның бирелеше, автор тарафын- нан аларның эчке дөньясының күр -кәм, матур сыйфатларының тасвирлануы		
23	Сибгат Хәким. “Торыгыз Мусалар!” , “Татарлар елмаеп үлделәр”, “Бакчачылар” шигырьләре	1	Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә. Язучының яшь буынны тәрбияләүгә керткән өлешен билгеләү.. Яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе. Патриотик тәрбия		
24	БСҮ. Сочинение “Татарлар елмаеп үлделәр	1	Үз фикереңне әйтә белү күнекмәләренә ия булу		
25	Нәҗар Нәҗми. “Татар теле” шигыре	1	Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә. Туган телнең кадере		
26	Гөлшат Зәйнашева. “Туган җирем – Татарстан”	1	Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Туган җирем-Татарстан” шигыре белән танышу		
27-28	Мөхәммәт Мәһдиев. “Без кырык беренче ел балалары” әсәре	2	Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Әсәрдә сугыш чоры балаларының авыр язмышы бирелеше		
29-30	Туфан Миңнуллин. “Монда тудык, монда үстек” әсәре	2	Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә Үз фикереңне белдерә белү		
31	Еллык контроль эш	1	. Сочинение-фикерләү		
32	Марсель Галиев «**Нигез**» әсәре	1	Тормыш юлы, иҗаты турында кыскача белешмә. Туган туфрак кадере.		
33	Иван Крылов. “Аккош, Чуртан һәм Кысла” , “Бүре һәм Бәрән” мәсәлләре	1	Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Әсәрләргә анализ ясый белү		
34	. А.Пушкин. “Кышкы кич”, “ Җырчы” шигырьләре	1	Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Туган җирем-Татарстан” шигыре белән танышу		